СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

10.10.2022 № 24/4

На №__________от______________

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Тукай муниципаль районы Советы карары проекты

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, муниципаль район уставының 95, 96 статьялары нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 14/5 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын 1 кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә һәм аны халык тыңлауларына чыгарырга.

2. Расларга:

- «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын 1 кушымта нигезендә;
- «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 2 кушымта нигезендә.
- «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибен 3 кушымта нигезендә.

3. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын 2022 елның 31 октябрендә 18.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча үткәрергә дип билгеләргә: ТР, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт, 2 кат (муниципаль район Советының утырышлар залы).

4. Түбәндәге составта халык тыңлауларын үткәрү буенча комиссия төзергә:

1) Закиров Рөстәм Илдус улы – муниципаль район Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе;

2) Әбделманова Роза Николаевна – комиссия әгъзасы;

3) Бухарина Наталья Владимировна – комиссия әгъзасы.

5. Халык тыңлауларын үткәрү буенча комиссиягә халык тыңлауларын үткәрүне, әлеге карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә халык тыңлауларында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Совет каравына кертергә.

7. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев